Кириллова З.Н.

Казан

# XX ГАСЫР БАШЫНДА КЕРӘШЕННӘР

XX гасыр башы татар халкы өчен генә түгел, ә аның бер этник төркемен тәшкил иткән керәшеннәр өчен дә милли үзаң уяну чоры була. 1905-1907 елгы революция вакытында ук күренекле педагог, җәмәгать эшлеклесе Роман Даулей һәм шагыйрь, драматург Давид Григорьев (Саврушевский) керәшеннәр өчен газета чыгару уе белән яналар [Глухов: 325], ләкин бу теләкне тормышка ашыру өчен мөмкинлек бирелми. Бары I Бөтендөнья сугышы барган вакытта – 1915 елда гына Вятка (хәзерге Киров – З.К.) шәһәрендә Петр Глезденев тарафыннан керәшен телендә "Сугыш хәбәрләре" газетасы һәм Уфа шәһәрендә Степан Матвеев редакторлыгында "Дус" газетасы дөнья күрә. Ләкин бу газеталар озын гомерле булмый: беренчесе бер елдан, икенчесе ике елдан соң чыгудан туктый [Глухов: 355].

1917 елгы Февраль революциясеннән соң керәшен мили оешмасы төзелә. Аңа нигез салучыларның иң күренеклеләре – Давид Григорьев һәм Иван Михеев (педагог, этнограф һәм әдип).

Әлеге милли оешмадан тыш, Октябрь борылышыннан соң РСФСР Милли эшләр халык комиссариаты каршында Үзәк керәшен бүлеге төзелә; Татарстан үзәк башкарма комитеты, партиянең Татарстан өлкә комитеты һәм Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе каршында керәшен секцияләре оештырыла; Мәгариф комиссариаты карамагындагы Гыйльми үзәктә (Академцентр) керәшен методик подкомиссиясе эшчәнлеген җәелдерә.

1917-1918 елларда керәшен милли оешмасы тарафыннан "Керәшен" дип аталган иҗтимагый-сәяси газета чыгарыла. Шулай ук Алабуга шәһәрендә "Алга барыек!" (редакторы – Г.И.Зубков), Минзәләдә "Хәбәрләр" газеталарының берничә номеры дөнья күрә. Кызыл армеецлар өчен 1918-1919 елларда "Кызыл салдат", 1919-1921 елларда "Кызыл әләм" газеталары, 1921-1922 елларда "Белемнек" журналы (барысының да редакторы – И.Алексеев) нәшер ителә.

1922 елдан 1930 елга кадәр исә Татарстан өлкә комитеты керәшен секциясе тарафыннан атналык “Киңәш” газетасы чыгарыла.

Моннан тыш, 1863 елда төзелгән Керәшен татар укытучылар мәктәбе нигезендә 1918 елда Керәшен укытучылар семинариясе оештырыла, ул исә 1922 елда Керәшен педагогия техникумына үзгәртелә. 1918 елдан аның мөдире вазифасын күренекле педагог, татарлар арасыннан педагогика фәннәре буенча беренче доктор Василий Горохов башкара.

1918 елда керәшен совет күчмә театры оештырыла. Баш режиссеры Захар Данилов җитәкчелегендә ул 1922 елга кадәр халык массаларына хезмәт күрсәтә [Глухов: 325-326].

1919 елда Үзәк керәшен нәшрияты оештырыла. Аның баш редакторы вазифасын Игнат Алексеев башкара. ТР Дәүләт нәшриятының керәшен бүлеге сыйфатында эшләсә дә, әлеге нәшрият шактый мөстәкыйльлеккә ия була. 1920-1921 елларда Дәүләт нәшриятының бик авыр икътисади шартларда эшләве, ә керәшен бүлегенең матди яктан яхшырак хәлдә булуы һәм бөтен Дәүләт нәшрияты чыгарган күләмдә китаплар нәшер итә алуы да аның автономрак хәлдә яшәвен раслый. Мәсәлән, Дәүләт нәшрияты 1919-1921 елларда 32 китап чыгарса, керәшен нәшрияты исә 34 исемдәге китап һәм җыентыклар нәшер итә [Каримуллин: 133; Глухов: 327]. Болар – беренче чиратта, керәшен мәктәпләре өчен дәреслекләр, иҗтимагый-сәяси хезмәтләр һәм әдәби әсәрләр. Алар арасыннан да төп урынны, билгеле, социализм идеяләрен пропагандалау, совет хөкүмәтенең сәясәтен һәм бурычларын аңлату характерындагы һәм дингә каршы чыгарылган китаплар алып тора. Шулай ук медицина, терлекчелек, ветеринария, бакчачылык буенча хезмәтләр; Н.В.Гоголь, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов әсәрләренең тәрҗемәләре дә очрый. Гомумән, нәшрият чыгарган китапларның күпчелеген Д.Аппакова, В.Филиппов, И.Алексеев, Л.Ишкинов, Н.Белугин, Н.Тимофеев һ.б. тарафыннан башкарылган тәрҗемәләр тәшкил итә. Оригиналь әсәрләрдән исә Д.Григорьев-Саврушевскийның “Пролетариат куәте” дип аталган шигырьләр җыентыгын һәм керәшен шагыйрьләренең шигырьләре тупланган “Сандугач” китабын күрсәтергә мөмкин [Каримуллин: 134].

Керәшен нәшрияты тарафыннан чыгарылган китаплар рус графикасында бастырыла. Бу китаплар, бер яктан, керәшен татарлары өчен XIX гасыр уртасыннан ук таныш булган графикага нигезләнеп, алар арасында социализм идеяләрен таратуга хезмәт итсәләр дә, икенче яктан, керәшеннәрне татарлардан һәм бай татар әдәбиятыннан тагын да ераклаштыралар. Керәшеннәр өчен аерым шрифтта китаплар бастыру эше хөкүмәт өчен кыйбатка да төшә, шулай ук миссионерларның дин нигезендә халыкның бер өлешен этнос итеп аерып чыгару сәясәтен объектив рәвештә дәвам итүгә дә китерә [Каримуллин: 134-135].

Күп гасырлар буе мөселман татарларга каршы куелып килгән керәшеннәр арасында да әлеге идеяләрне яклаучылар шактый күп була. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң бигрәк тә “Сугыш хәбәрләре”, “Дус” һәм “Керәшен” газеталарында керәшеннәрнең аерым халык (народность) булу идеясе алга сөрелә, “Керәшеннәр – аерым милләт” лозунгы күтәрелә. Бу чорда керәшен милли хәрәкәтенең лидерларын, бер яктан, фронттан кайткан офицер һәм солдатлар (И.Алексеев, В.Горохов, Г.Подъячев, Н.Соловьев, Н.Комиссаров, С.Тимофеев һ.б.), икенче яктан, элекке интеллигенция вәкилләре (Р.Даулей, Н.Егоров, Д.Григорьев, И.Михеев, С.Матвеев һ.б.) тәшкил итә, шулай ук керәшен укытучылары да бу идеянең актив тарафдарлары булып торалар.

Ләкин керәшен милли хәрәкәтенең сафлары бердәм һәм оешкан булмый, нәтиҗәдә Октябрь борылышыннан соң ук аларның күбесе, совет хөкүмәтен яклап, “милли социалистик төзелеш” юлына басалар [Глухов: 333-334]. Ныклы нигезгә корылмаган аерым халык яки милләт булу идеясе әкренләп юкка чыга. Буталчык чорда – революцияләр һәм гражданнар сугышы вакытында әле бу фикерләр өчен мөмкинлек калдырылса да, 1920 елдан башлап, татар халкы белән бердәм булып, “якты киләчәк һәм сыйнфый, милли изүсез ирекле җәмгыять төзү өчен көрәшү” идеясе беренче урынга куела.

Татарлар белән керәшеннәр арасындагы каршылыкны юкка чыгаруның беренче адымнары 1920 елның июлендә булган керәшеннәрнең I Бөтенроссия эшче-крестъян һәм кызыл армеецлар съездында ясала. Съездда капма-каршы

ике агым формалаша: берсе – “мәдәни-политик автономия” яклылар, икенчесе – “татарлар белән якынаюны” хуплаучылар. Съезд вакытында бу ике агым вәкилләре килешүгә килә алмыйлар, әмма резолюциядә татарлар белән мөнәсәбәт хакында түбәндәге карар урын ала: “Керәшеннәрнең аз санлы булуын, татарлар һәм башка халыклар арасында таралып урнашуын, җитәрлек дәрәҗәдә әзерлекле сәяси һәм мәдәни эшлеклеләрнең җитешмәвен, шулай ук урыннарда татарлар белән бергәләп эшләү фактларын исәпкә алып, татарларның сәяси-агарту оешмалары белән тыгыз аралашып эшләү өчен барлык чараларны да күрергә”. Шул ук съездның мәктәп секциясе тарафыннан керәшен мәктәпләрендә, Н.Ильминский транскрипциясен кире кагып, гарәп шрифтына нигезләнгән татар язуын кертү хакындагы карар да кабул ителә [НА РТ, ф. 732, оп. 1, д. 262, лл. 14-15].

Бу карарлар алга таба да һәр ел саен уздырылган керәшен коммунистларының өлкә конференцияләрендә, керәшен мәгариф хезмәткәрләре съездларында, керәшен яшьләренең өлкә конференцияләрендә кабатлана һәм тагын да тирәнәйтелә. Мәсәлән, 1923 елгы керәшен мәктәп хезмәткәрләре съезды карарларында “керәшеннәр арасында татар телен гамәлгә куюның мөһимлеге һәм кирәклеге барлык хезмәткәрләр тарафыннан да танылa” дигән сүзләр дә урын ала. Шул ук елда керәшен коммунистларының өлкә конференциясендә “без – татарлар һәм мөселманлыкка күчмичә дә татар булып калырга мөмкин” дигән сүзләр ассызыклана [НА РТ, ф. 732, оп. 1, д. 262, лл. 13-16].

Шулай итеп, 1920 елдан татарлар белән якынаю һәм татар телен гамәлгә кую ягына борылыш этабы башлана. Ләкин Керәшен коллегиясе (ул Казан губерна милләтләр бүлегенең керәшен бүлекчәсе урынына төзелгән була) 1922 елга кадәр “милли-мәдәни автономия” линиясе буенча бара, ә 1922 елда шул ук орган “керәшеннәрне татарлар белән механик рәвештә кушуны яклый башлый (мәктәпләрне, газеталарны берләштереп)”. Шушы нигездә керәшеннәр ягыннан каршылыклар килеп чыга – юкка гына 1922 елны керәшен проблемасы буенча махсус комиссия төзелмәгәндер. Комиссия нәтиҗәләреннән күренгәнчә,

“керәшеннәрне татар массалары белән якынайту һәм кушу эше ялган милләтчеләрне фаш итү.., миссионерлар һәм клерикаль элементлар йогынтысыннан арындыру аркылы алып барылган”. Шулай ук керәшеннәрнең “барлыкка килүләре” киң яктыртылган, ә мәктәпләрдә уку “татар язуына” күчерелгән [Исхаков: 30; Кряшенский вопрос].

Керәшен мәктәпләрен гарәп графикасында язуга күчерү өчен, Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе тәкъдиме белән, 1922 елдан керәшен укытучылары өчен кыска вакытлы курслар эшли башлый. Курсларны эшләтүгә Татарстан үзәк башкарма комитеты һәм Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе сәркатибе вазифаларын башкаручы, ул вакытта 25 яшьлек Николай Петров зур ярдәм итә. Ул үз тирәсенә бу эшне башкарып чыга алырлык педагогларны җыя, курсларны ачу һәм яшәтү өчен акча табу, эшкә юнәлеш бирү кебек чаралар да аның тарафыннан башкарыла [НА РТ, ф. 732, оп. 1, д. 531, л. 180].

1922 елның 25 июненә 110 урынга исәпләнгән беренче чакырылыш уңышлы булмый. Әлеге курсларның уку планы, укытучылар составы, сметасы, курсларның аппараты һәм администрациясе бик төгәл билгеләнгән булса да [НА РТ, ф. 732, оп. 1, д. 122, л. 164], архив чыганакларыннан күренгәнчә, җәй көне курсларга бик аз санлы курсантлар килү сәбәпле, аларны таратырга туры килә [НА РТ, ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 29]. Икенче чакырылыш шул ук елның 1 сентябрендә була: 70 керәшен укытучысы 4 айлык курсларга җыела һәм декабрь ахырында рәсми рәвештә укуларны бетереп чыга. Шулай ук 1923 елда – 96, 1924 елда – 143 һәм 1925 елда 60 керәшен укытучысы курсларда әзерлек үтә [НА РТ, ф. 732, оп. 1, д. 527, л. 29; За 5 лет: 45]. Курсларда татар теле һәм язуына аеруча зур урын бирелә. Мәсәлән, 1924 елгы курсларның уку планына күз салсак, теоретик өлеш 128 сәгатьне тәшкил итеп, шуларның 60ы, ягъни яртысы диярлек, татар теленә багышланган. Моннан тыш, гамәли өлештә татар теле укыту методикасына 20 сәгать бүлеп бирелгән [НА РТ, ф. 732, оп. 1, д. 531, л. 79].

Шул рәвешчә, Татарстандагы керәшен мәктәпләренең барлык укытучылары да курсларда укып, гарәп шрифты нигезендәге татар язуын тирәнтен үзләштерәләр. Нәтиҗәдә, 1923/1924 уку елыннан ук инде керәшен мәктәпләрендә татар язуы махсус фән буларак үтелә башлый, ә кайбер урыннарда исә ул төп язуга әйләнә [За 5 лет: 45; Отчет 1923: 43; Отчет 1925: 37].

Керәшен мәктәпләрен татар теле дәреслекләре белән тәэмин итү максатында, керәшен укытучылары тарафыннан да дәреслекләр, уку китаплары языла. Мәсәлән, 1922 елның октябрь-ноябрь айларында Мәгариф комиссариатының татар редакциясе коллегиясе тарафыннан Харитоновның “Бүләк” исемле татар әлифбасын басарга дигән карар кабул ителә [НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 410, л. 310] (ул беренче тапкыр 1912 елда басылып чыккан була – З.К.). Шулай ук күренекле педагог Семен Любов тарафыннан керәшен мәктәпләренең башлангыч сыйныфлары өчен төзелгән “Беренче адым” дип аталган уку китабы да керәшеннәр арасында зур популярлык казана.

1923 елның 23 сентябрендә керәшен методик подкомиссиясе тарафыннан И.Алексеевның Г.Шәрәф белән язган әлифбасы тиз арада бастырып таратырга тәкъдим ителә [НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 410, лл. 151-152]. Бу китап “Якты юл. Керәшен школалары өчен букварь һәм беренче уку китабы” исеме белән 1926 елда басылып чыга. Әлифба Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе соравы буенча төзелә, кириллица белән таныш укучыларны гарәп транскрипциясендә укырга һәм язарга өйрәтү максатын күздә тота. Гарәп язуының иске һәм яңа имля вариантлары, шулай ук керәшен алфавиты хәрефләре дә параллель рәвештә китерелә. Керәшеннәрнең сөйләм үзенчәлекләре исәпкә алына, мәсәлән, кайбер сүзләр керәшен һәм татар әйтелеш вариантларында биреп барыла. Күренгәнчә, әлеге дәреслекләр керәшен мәктәпләрен гарәп графикасында язуга күчерү өчен хезмәт итәләр.

Ләкин, билгеле булганча, 1926-1927 елларда инде латин шрифтына күчү кампаниясе башлана, һәм керәшеннәр өчен гарәп язуын өйрәнүнең кирәге калмый. 1928 елның гыйнварында булган төрки мәгариф хезмәткәрләренең I

Бөтенроссия съездында “Керәшеннәр арасында эшләү хакында”гы мәсьәлә дә карала. Съезд карарлары нигезендә, барлык төрки халыкларны, шул исәптән керәшеннәрне дә, латин графикасына күчерү хакындагы тәкъдим кабул ителә [Каримуллин: 136].

1928 елда И.Алексеевның А.Григорьев белән язган “Яңа тормыш. Керәшен школалары өчен әлифба” һәм, шуның дәвамы буларак, “Яңа тормыш. Керәшен школалары өчен әлифбадан соң уку китабы” инде яңалиф шрифтында басылып чыга. Алда саналган дәреслек һәм уку китаплары нигездә Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе тарафыннан бушлай таратылалар.

Өлкә комитетның 1922 елда керәшен мәсьәләсе буенча төзелгән, алдарак искә алынган комиссиясе 1925 елда “керәшен укытучыларының күпчелеге үзләренең элекке карашларыннан баш тартты, керәшен массаларының психологиясендә ... татар массалары белән якынаюда билгеле бер үзгәреш булдырылды” [Кряшенский вопрос] дигән нәтиҗәгә килсә дә, 1926 елгы халыкны исәпкә алу вакытында Идел-Урал регионында 120 мең кеше үзен милләте буенча “керәшен халкыннан”, дип яздыра (шушы төбәктәге татарларның 4,8 проценты). Әле шуның өстенә керәшеннәрнең бер төркеме – нагайбәкләр үзләрен “халык”, дип яздыралар (11,2 мең кеше) [Исхаков: 31]. Күренгәнчә, бу елларда мәсьәлә шактый катлаулы булган.

XX гасыр башында күтәренке рух белән башланып киткән керәшен хәрәкәте 20 нче еллар ахырында һәм бигрәк тә 30 нчы елларда бетүгә дучар ителә. Мәсәлән, 1930 елда Керәшен педагогия техникумы ябыла, шул ук елда “Киңәш” газетасы чыгудан туктый [Глухов: 326]; төрле оешмалардагы керәшен бүлекләре һәм секцияләре бетерелә. Моңа, билгеле, илдә алып барылган гомуми сәясәт һәм милләтләрне берләштерү идеясе дә йогынты ясый. Керәшеннәр арасыннан да шактый күп зыялы һәм алдынгы карашлы шәхесләр репрессияләнеп юкка чыгарыла (Д.Григорьев (Саврушевский), Г.Подъячев, И.Михеев, В.Гордов, С.Домолазов һ.б.), кайберләренә исә хезмәт итү өчен мөмкинлек бирелми.

Бары 90 нчы елларда гына керәшен милли хәрәкәте яңадан үзенең эшчәнлеген җәелдерә алды. 1991 елдан “Керәшен сүзе” газетасы чыга башлады, (хәзер ул “Туганайлар” исеме белән нәшер ителә), “Ватаным Татарстан” һәм кайбер район газеталарында махсус кушымталар дөнья күрде. 1991 елның көзендә керәшеннәрнең Казан милли-агарту җәмгыяте һәм аның урыннарда күп санлы бүлекләре төзелде. Бу оешмалар керәшеннәрнең милли гореф-гадәтләрен, йолаларын, җыр һәм биюләрен саклап калу юнәлешендә зур эш башкаралар. Хәзерге вакытта да керәшен җәмгыятенең һәм керәшеннәрнең кайбер вәкилләре аерым халык булу фикерен алга сөрәләр, әмма күпчелеге, татар халкы белән бердәм булган хәлдә, этник үзенчәлекләрне саклап калуны яклый.

**Әдәбият**

Глухов М.С. Tatarica. Энциклопедия. – Казан: Ватан, 1997. – 502 б.

За 5 лет. К 5-й годовщине провозглашения ТССР. – Казань: Изд. ТЦИК, 1925. – 208 с.

Исхаков Д.М. Керәшеннәр. Тарихи-этнографик очерк // Идел. – 1994. – №6. – Б. 23-31.

Каримуллин А.Г. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917-1932). – Казань: Тат. кн. изд-во, 1999. – 320 с.

Кряшенский вопрос (по материалам Комиссии Областкома) // Красная Татария. – 1925. – №274.

Отчет ЦИК и СНК за время с 3-го по 4-й съезд Советов. – Казань: Тип. «Красный Печатник», 1923. – 304 с.

Отчет ЦИК и СНК к 5-му съезду Советов. – Казань: Изд. ТЦИК, 1925. – 200 с.